РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«30» сентябрь 2022 ел Олы Кайбыч ав. № 148

Кайбыч муниципаль районы Советының 2016 елның 11 апрелендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен контрольләү турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы Советының 2016 елның 11 апрелендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә 8 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, хисап чорына цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алуга кагылышлы алыш-бирешнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында үз

чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр».

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Кайбыч муниципаль районы Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 11 июлендәге 130 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарны үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Айзатуллова Р.Г.га йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин